**СОВЕТ НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422630 ,РТ, Лаишевский район,
село нармонка, ул.Молодежная, д.12а
Тел: 8 (84378) 4-62-24
Факс: 8 (84378) 4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН НАРМОНКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422610 Лаеш районы,Нармонка авылы
Яшьлэр ур., 12 а анчейорт
Тел: 8 (84378) 4-62-24
Факс: 8 (84378) 4-62-24

**2024лның 11 ноябре** **230/2 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге составына керүче Тетеево торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 3 ноябрендәге «2025 елда Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегенең Тетеево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1875 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризалыгыгыз бармы, моңа балачактан көндезге формада белем алучы студентлар һәм инвалидларны исәпкә алмыйча, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны-

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү эшләре өчен түләүгә юллау белән килешәсезме дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

-сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 160 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 85 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында 85 катнашучы «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

"Каршы" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегенең Тетеево торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Тетеево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салым акчаларын 1875 сум күләмендә

кертергә. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү эшләре өчен түләүгә юллау белән килешәсезме дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге составына керүче Тетеево торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 08 ноябрендәге 230/1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Нармонка авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.Ф. Мөбәрәкшин

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Нармонка
авыл җирлеге Советы рәисе И.Ф. Мөбәрәкшин